ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КОШТАУЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2024 ел, 19 февраль №146

Коштаулы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль хакындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 5 февралендәге 124 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Коштаулы авыл җирлеге советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге Советының "Коштаулы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2021 елның 11 октябрендәге 53 номерлы карары белән расланган Коштаулы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.7 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) планлаштыру структурасы элементлары - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), яр буе, гражданнарның бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе үз ихтыяҗлары өчен;»;

1.7 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) урам-юл челтәре элементлары - урам, проспект, тыкрык, юл, мәйдан, бульвар, тупик, съезд, шоссе, аллея һәм башкалар;".

2.Әлеге карарны а Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм җирлекнең мәгълүмат стендлары аша халыкка җиткерергә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлек башлыгына йөкләргә.

Коштаулы авыл җирлеге Башлыгы,
Коштаулы авыл җирлеге Советы рәисе Х.Ф.Сабиров